


МӨДӘРРИС МӨСИФУЛЛИН

АУЧЫ МӘРГӘН МАҖАРАЛАРЫ






МӨДӘРРИС МӨСИФУЛЛИН



АУЧЫ МӘРГӘН МАҖАРАЛАРЫ



Рәссамнары Зөфәр һәм Заһир Хәкимовлар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1999

АУЧЫ МӘРГӘН МАҖАРАЛАРЫ

(Әкият-легенда)

Башта карт аучы Атанбай хакында берничә сүз әйтеп китү кирәктер. Шәҗәрәдә язылганнар дөрес булса, аның ата-бабалары аучылык, балыкчылык белән шөгыльләнеп көн күргән. Чөнки Атанбайлар яшәгән төбәк сәер һәм сихри көчләр очраган биек-биек таулардан, төпсез күктән, төрле киек-җанварлар белән тулган кара урманнардан, могҗизалы күлләрдән торган. Атанбай тормышында истә калырлык иң зур вакыйга моннан унсигез ел элек булган.

Рамазан аеның җиденче көнендә, кич, чираттагы аудан кайтышлый, Атанбай үзенең тирмәсе янында бер төргәк күргән. Төргәкне ачып караса, ышанмый тора икән — анда, күзләрен мөлдерәтеп, бер малай карап ята, ди. Менә шул минуттан бу табылдык Атанбайның улы булып киткән. Бераз үсә төшкәч, Атанбай аны үзе белән ауга йөртә башлаган. Беренче көннәрдән үк малай үзенең төз атуы белән аны хәйран калдырган. Карт аучы бик теләп табылдык малайга Мәргән дип исем биргән. Менә шулай булган, дип сөйлиләр, Мәргәннең баштагы язмышы. Ә хәзер яшь аучы урман-таулар арасында көн дә төрле маҗараларга очрый икән...

БӨРКЕТ




Кошларны, киекләрне сәбәпсез атма,— дип кисәткән Атанбай Мәргәнне чираттагы сәфәренә озатканда.— Җәя тартып ук атучылар күп ул, ә менә киләчәк хакында борчылучылар сирәк очрый.

Егет эндәшмәгән, ялбыр яллы Толпарын түбәсе болытларга ашкан Аждаһа тавына таба борган. Бу таш кыяның исеме җисеменә туры килгән — ерактан ук зәһәр еланны хәтерләтеп торган ул. Ә анда дөнья киткән Аждаһа бик күп батырларның башына җиткән, ди, дөрес булса. Замана җилләре аның сихри көче турындагы риваятьләрне безнең көннәргә дә китереп җиткергән. Ә баһадир исеме алган кайсы гына пәһлеван егетнең кара көчләр белән алышып карыйсы килмәсен ди инде?! Мәргән дә шул юлны сайлаган.

Менә ул таш өстендә канаты каерылган Бөркетне күреп алган һәм Толпарын шып туктаткан.

— Син аучы һөнәренең серләрен, нечкәлекләрен бик тырышып һәм яратып өйрәндең,— дигән Бөркет,— югарыдан күзәтеп очтым.

— Ә синең Аждаһа тавындагы сигез аяклы еланны, Еланбалыкны, Аждаһаның үзен күргәнең бармы? — дип сораган Мәргән.



Бу сүзләрне ишеткәч, Бөркет җитдиләнгән, ди.

— Ашыкма, егет,— дигән ул Мәргәнгә, туры карап.— Аларны моңа тиклем бер генә адәм баласы да көч белән җиңә алмаган. Серен, тылсымын белмиләр икән.

— Ә аны кайдан белеп була? — дип сораган Мәргән, түземсезләнеп.

— Сабыр бул, тормыш үзе күп нәрсәгә өйрәтә! — Горур кош тау ягына күз салган.— Күрәштә, алышта син җиңәрсең, моңа ышанам. Ә менә минем бәйге ничек тәмамланыр, ансы билгесез.

Мәргән аптырап кошка караган.

— Нинди бәйге ул? Сезнең арада да андый йолалар бармыни?

— Озакламый минем элекке хуҗам Арсланбай, тирә-яктагы аучыларны чакырып, зур җыен үткәрергә чамалый. Беләсеңме, анда күпме кошлар, киекләр һәлак булачак. Күрсәң, исең-акылың китәрлек. Менә шул көнгә тиклем савыксам, Арсланбайдан үч алачакмын.

— Яралы кошка ярдәм кулын сузарга бурычлымын,— дигән Мәргән, Бөркетнең каерылган канатын карап.— Тик кешеләрдән үч алырга җыенуыңны гына хупламыйм.

Горур кош, сүзсез генә тыңлап торган да, болай дип сөйләп киткән, ди: «Арсланбайның синең кебек яшь, көчле чагы иде. Без аның белән моннан еракта, Каф таулары ягында ауда очраштык. Мин аңарга ияреп бу якларга кайттым һәм гомерем буе

аңа хезмәт иттем. Әмма хуҗам картайган саен комсызланды, байлыгы арткан саен күзе кызды. Беркөн нәүбәттәгеауга чыккач, мин карышып карадым һәм менә аның нәтиҗәсе: ул миңа атты, аңлыйсыңмы, атты. Мин мәтәлеп ташлар арасына барып төштем, ә Арсланбай шашынып көлде. Менә шулай, баегач, элекке дуслар кирәкмәс булды аңа. Ул тугры дуслыкка хыянәт итте. Ә без — Бөркетләр — горур кошлар...

— Юк,— дигән Мәргән, аның белән килешмичә.— Синең фикерне хуплый алмыйм.

Бөркет яшь аучыга сынаулы караш ташлаган.

— Кем дә булса Арсланбайны туктатырга тиеш бит. Югыйсә... Хәер, Арсланбай һәм аның иярченнәренең дуамаллыгын күреп үзең дә шаккатарсың әле. Тик шуны кисәтәм: син тәвәккәл, кыю егет. Әмма Арсланбайга каршы чыкма.

— Ни өчен?

— Моны син соңрак аңларсың.— Бөркет беразга тынып калган, ди. Аннан биек тау ягына карап алган.— Юккамыни Арсланбайны зәһәр, хәйләкәр, комсыз елан дип атыйлар. Дошманың көчле булса, бигрәк тә ашыгырга ярамый.

— Дөрес, көчле дошманга ныклап уйланган фикер, хәйлә белән генә каршы торып була,— дип өстәгән Мәргән.

— Очкан кошка караганда, ботакта утырганын атып төшерүе җиңелрәк,— дигән Бөркет.

Мәргән җавапсыз калмаган:

— Оста аучы кошны очканда да атып ала,— дип өстәп куйган.

Алар башкача бәхәсләшмәгәннәр. Мәргән, Бөркетне кулбашына утырткан да, Толпарына атланып, Төпсезкүл ягына юл алган.

Шушы сөйләшүдән соң күп тә үтмәгән, Арсланбайдан чапкын килгән. Бу юлы аучылар җыенына Атанбай унсигез яше тулган Мәргәнне дә алып барырга тиеш булган.

Алар иртә таңнан юлга чыкканнар. Киткәндә икесе дә таш өстендә утырган Бөркет белән хушлашканнар. Юлда аларга тагын берничә аучы килеп кушылган. Билгеләнгән урынга җиткәнче галәмәт күбәеп киткәннәр. Кешеләр бер-берсеннән хәл-әхвәл сорашкан арада, акланга ук кебек атылып, җайдак килеп кергән.

— Арсланбайга сәлам! — дип кычкырган аучылар, бертавыштан. Тегесе акланны өч тапкыр урап чыккан да тезгенен шундый итеп тарткан, ди, хәтта Аргамак, яман кешнәп, арт аякларына баскан.

— Яшәсен Арсланбай! — дип алкышлаганнар аучылар, бу тамашага хәйран калып. Ә үзләренең күзләре Аргамакта икән — аты да соң аты! Күзләрендә ут, ялында, койрыгында кояш нурлары җемелди, имеш. Дөрес булса, Арсланбай аны бик зур хакка казахлардан сатып алган, ди. Мәргән яхшылап атка күз дә сала алмый калган. Арсланбай кергәндәге кебек җилдереп чыгып та киткән. Аучылар аның артыннан чапканнар. Мәргән дә аларның артыннан калмаска тырышкан.

— Бер аучы да акланга буш кул белән кайтырга тиеш түгел,— дип аңлаткан Атанбай ике кошны атып алгач.— Арсланбай җебегәннәрне яратмый.

Йөри торгач, тауның икенче ягына килеп чыктылар, ди, болар. Шулчак Төпсезкүл ягыннан җан-фәрманга чабып килгән кыр кәҗәләре күренгән. Артларыннан очкан уклар аларны берәмләп-берәмләп җиргә егып сала икән. Мескеннәр мәтәлеп егыла, аучылар кычкырып көләләр, ди. Мәргән аптырап остазына караган. Ә тегесе, нишләптер, күзләрен яшергән.

Төштән соң барысы да акланга җыелган. Аучылар, бер-берсен уздырырга тырышып, Арсланбай яткан түшәк алдына корбаннарын тезеп салганнар. Җансыз кош-корт, киек-җанварлардан тау өелгән.

Арсланбай бик канәгать икән. Аның иярченнәре аучыларны кымыз белән сыйлый башлаган. Шулчак бер кәҗә кычкырып җибәргән. Барысы да тынып калган.

— Мә-ә-ә,— ди икән җәрәхәтләнгән кәҗә.

Мәргән сикереп торган. «Ялгыз каен янында,— дип ишетелгән аңа бахырның ачы тавышы,— ташлар арасында бәләкәчләрем ятып калды, зинһар, шуларны коткарыгыз...»

— Әй, кешеләр,— дигән Мәргән, аучыларга карап.— Бирегез миңа бу яралы хайванны, үтенеп сорыйм.

Барысының да карашы Арсланбайга төбәлгән. Ул кымыз эчкән чәркәсен ялчысына тоттырган да ук белән җәя алып кәҗә янына килгән. Аның ачуы йөзенә чыккан.

— Мондагы табышның барысы да минеке,— дигән ул, бүре кебек улап.— Бирмим, юк...

Кинәт Арсланбай калтырап киткән. Һавадан зур тизлек белән очып төшкән Бөркет томшыгы белән аның башына суккан да кире күккә күтәрелә башлаган. Тик йөзләгән укның берничәсе кошның юлын кискән. Бөркет бер-ике талпынган да җирдә хәрәкәтсез яткан Арсланбай янына килеп төшкән. Мәргән шунда йөгергән. Горур кошның тәне суынып бара икән. Ул соңгы сулышын алып:

— Мин бер Аждаһаның башына җиттем. Икенчесе синең өстә,— дип әйтә алган.

— Кешеләр! — дип кычкырган Мәргән, җансыз кошны өскә күтәреп.— Бөркет кебек горур булыйк!

Шуннан соң Мәргән коштан ишеткәннәрен түкми-чәчми аучыларга сөйләгән, ди. Азактан Бөркетне алып, кәҗәне җилкәсенә салган да Ялгыз каен янына киткән.

— Яшәсен Мәргән! — дип кычкырып калганнар арттан аучылар.

Бу җыеннан Атанбайга, гомерендә беренче тапкыр, үзенең өйрәнчегенә өчен горурланып кайтырга туры килгән, ди.



ЯУ КИЛГӘЧ



Яхшылык яманлык тудырмас. Мәргән Бөркетне Аждаһа тавы итәгенә күмеп, кәҗәне алган да Ялгыз каен янына киткән. Бәхет шулдыр — тегенең бәрәннәре исән-саулар, бәәлдәшеп үлән ашап йөриләр икән. Алар, яралы аналарының тавышына ияреп, Атанбайның тирмәсенә җиткәнче йөгереп кайтканнар.

Көннәр үтә торган. Иртә таңнан караңгы төшкәнче, Мәргән күзләрен Аждаһа тавыннан алмаган: «Нинди сәер, сихри көч ул? Ә бәлки, Арсланбай кебек комсызларның хәйлә капчыгыдыр?» Ничек кенә булмасын, сихри көч үзен сиздерә, аның тарту куәте егеткә бер генә минутка да тынычлык бирми, ди.

Яшь аучының язмышы, әүлияләр әйтүенә караганда, Аждаһа тавына барганчы, төрле мажаралардан, могҗизалардан торачак икән. Шул чакта алган чыныгулар, гыйлем, осталык Мәргәнне зур бәйгеләрдә җиңүче, тәҗрибәле сугышчы итәчәк, ди. Хәер, болары алдагы көннәрдә. Ә бүгенге дәвер, хәлиткеч көрәшләрдә батырлар көч-куәт, осталык, кирәк булса, соңгы сулышын, җанын бирергә әзер торган чор, ди.

Һәркемгә мәгълүм, аучылык белән шөгыльләнгән кешеләр аерым-аерым яшәгәннәр. Илгә дошман һөҗүм иткән очракта, батырлар бер-берсенә чапкын җибәргән. Бүген дә шулай килеп чыккан. Атанбай, илнең аксакалы, бу көрәшкә үзенең өйрәнчеген җибәрергә тиеш булган:

— Башсыз, аңсыз кешеләрдәй башта ук сугыш коралына ябышмагыз,— дигән ул Мәргәнгә.— Бәлки, тыныч килеш таралып була торгандыр?

Билгеле, егет бик нык дулкынланган. «Их, булсын иде янымда йөзьяшәр Бөркет,— дип уйлаган ул коралларын барлаганда,— үзенең киңәшләре белән ярдәм итәр иде...»

Сез Мәргәнне ук-җәя белән генә эш итә икән дип уйламагыз тагын. Алдагы мажараларда аның кыю, җитез, түземле сугышчы икәнен күрерсез. Остазы Атанбай шулай өйрәткән аны.

Ялбыр яллы Толпар, тиз арада Мәргәнне тирә-ягы текә кыялар белән уратып алынган зур акланга алып килгән. Борын заманнарда хәлиткеч бәрелешләр өчен аксакаллар сайлаган урын шушы икән. Күпләрнең каны коелган монда.

Мәргән, аклан уртасына басып, тирә-якны җентекләп карап чыккан. Түбәгә ишелеп төшәргә әзер кыялар аның күңеленә шом салган. «Әгәр дә югарыда коралланган батырлар басып торса,— дип уйлаган Мәргән,— бу дошманда курку хисе тудырачак...»

Акланга тагын берничә җайдак килеп кергән. Мәргән аларны баш иеп сәламләгән. Барысы да җыелып беткәч, план кора башлаганнар тегеләр. Бер уйласаң, көрәш — зур уен, ә анда хәйләкәр булу бик мөһим. Мәргән дә үзенең уй-фикерләрен әйтеп салган:

— Билгеле ки, төнге ял өчен дошман шушы акланны сайлаячак,— дигән ул, үзенең тәкъдимен исбатларга теләп.— Без кыя башларына урнашып аларны уратып алырбыз һәм сугышсыз гына китүләрен таләп итәрбез.

— Без бик аз,— дип каршы төшкән мыеклы аучы.

Мәргән елмаеп куйган да:

— Кыя артында күпме гаскәр барлыгы астан күренми,— дигән.— Безнең хәйләнең сере, асылы шул.

Билгеле, башка уй-фикерләр дә булган. Азактан килеп, Мәргәннең тәкъдименә тукталганнар.

— Әгәр дә дошман безнең серне сизсә,— дигән ул, коралларын барлап,— безнең башка чара юк, шушында алышырбыз. Ә хәзер читкәрәк китеп ял итик.

Кич җиткәч, чапкын дошман гаскәрләренең акланга килеп туплануын хәбәр иткән. Барысы да уйлаганча бара бит инде болай булгач. Җитмәсә, соңга калып булса да, елгыр аргамагына атланып, тирә-якка даны чыккан Ишбай батыр да килеп җиткән. Егетләрнең күңелләре күтәренке икән, йокылары да качкан, ди. Шулчак Мәргәннең башына тагын бер фикер килгән:

— Егетләр,— дигән ул,— нигә безгә таң атканын көтәргә? Бу вакытта дошман безне көтми, җитмәсә, алар арыган, йончыганнар. Атларны монда калдырып, сиздерми генә җәяү барыйк та камап алыйк.

Әле караңгы төшеп өлгермәгән булган. Шуңа күрә аклан уч төбедәй күренә икән. Беренче сүзне батырларның иң өлкәне, көр тавышлы Ишбай алган:

— Мин — Байгөбәк улы батыр Ишбай булам,— дип кычкырган ул, кинәт. Аның тавышы күк күкрәгәндәге кебек, таштан ташка бәрелеп дошманны калтыраткан.— Сез уратып алынгансыз.

Аклан уртасында торган тирмәдән дәрәҗәле генә атлап чыккан кеше, кыя башларына күз ташлаганнан соң, кулына кылыч алган да:

— Ә мин — бөек юлбашчы Әмир түрә булам,— дигән эре генә.— Башта Арсланбай чыксын, аның белән көч сынашасым килә. Бабайлардан калган йола шундый.

— Арсланбайны комсызлыгы харап итте,— дип җавап биргән Ишбай.— Ул хәзер теге дөньяда.

— Алай булгач, арагызда миңа каршы чыгардай батыр бармы? — Әмир түрә берничә адым алга атлаган. Әгәр дә булса, чыксын, җәллады булырмын.

Мәргән кылычын суырып алга атлаган:

— Кемнең батыр, кайсыбыз җәллад икәнен көрәш күрсәтер...

— Тукта! — дигән шулчак Ишбай батыр һәм Мәргәннең кулбашына тотынган.— Әмир түрә көчле, хәйләкәр адәм. Минем белән берәр хәл булса, көрәшне син дәвам итәрсең.

Ишбай батыр белән Әмир түрә калкулыкка менеп кара-каршы басканнар, ди. Беренче шарт — җәядән атышу икән. Көч сынашучылар, икесе ике якка иллешәр адым киткәннәр дә, җәяләрен тартып атып та җибәргәннәр. Ни гаҗәптер, сызгырып килгән уклар бер-берсенә бәрелеп җиргә төшкәннәр. Ә батырлар кылычларына ябышканнар. Кыска, бик кыска булган бу алыш: Әмир түрә аягын яралап, Ишбай батыр башын тотып җиргә егылган. Байгөбәк улы Ишбай батырның гомере шунда өзелгән, диләр.



— Тагын кем үзен батыр дип саный? — Әмир түрә аягына басып көлеп куйган.— Чыксын каршыма.

Мәргәннең яман ачуы чыккан. «Бу канечкечкә ни җитми? Күпме кешеләрнең гомерен өзәчәк бит бу адәм актыгы».

— Мин чыгам!

Әмир түрә яшь егеткә мыскыллы караш ташлаган да:

— Син кем өтеге? — дип сораган.

— Атанбай остазның өйрәнчеге, Мәргән булам! — Ул тиз генә кылычын кыныннан суырып алган.— Ияртеп килгән халкыңа соңгы теләкләреңне җиткереп кал.

— Кыю сөйлисең, егет,— дигән, ди, Әмир түрә, җитдиләнеп.— Башладык!

Мәргәннең җитезлеген, кылыч белән оста эш иткәнен күреп, хәтта дошманнар да хәйран калган, ди. Бу бәйге дә кыска булган. Әмир түрә күз ачып йомган арада башын тотып җиргә тәгәрәгән.

— Мин — аучы, — дип кычкырган Мәргән килгән халыкка. — Минем сугышасым, кан коясым килми.

Тирә-якта тынлык урнашкан. Билгеле, Әмир түрә исән булса, күптән алыш башланыр иде. Ул булмагач, котыртучы да юк икән. Моны Мәргән яхшы аңлаган. Башлыксыз гаскәр бит, бәлки кире борып булыр дип уйлаган.

— Без күп тапкырга артык, — дигән ул тегеләрнең икеләнеп торуын күргәч. — Мин сезгә исән-сау килеш кайтып китәргә тәкъдим итәм.

— Без дә аучылар, балыкчылар, — дип җаваплаганнар астан. — Әмир түрә куркытып, көчләп кенә алып килде. Без кире китәбез.

Шатлыклы тавышлардан тирә-якта кыялар ишелеп төшкән, диләр. Менә шулай тәмамланган, ди, Мәргәннең тагын бер мажарасы.

Ә Ишбай батырның кабере Урал тауларының берсендә, биек кыя башында, әле булса саклана, ди. Мәргән нәселеннән булган аучылар әле дә аның янына барып йөри икән, дөрес булса.



СУСЫЛУ



Берчак Атанбай сунардан борчылып кайткан.

— Бабайларның сөйләвенә караганда, — дигән ул, Мәргәннең иңбашына кулын салып, — безнең Төпсезкүлдә вакыты-вакыты белән коточкыч... Еланбалык пәйда булган. Ул, күл суларын пычратып, тирә-як мохиткә зур зыян китереп, агачларны тамыры белән актарып ташларга яраткан. Киекләр, хайваннар кырылган, кошлар сайрамас булган.

— Сәер хәл... Ә ул Еланбалыкны кем күргән?

— Сәер генә түгел, гаҗәпләнерлек хәл бу. Аның белән көрәшергә киткән батырларның берсе дә кире әйләнеп кайтмаган.

Мәргән остазына караган:

— Исеме — мәзәк — Еланбалык,— дигән ул, уйланып. — Тик аны күрүче булмагач исеме җисеменә туры килмәскә дә мөмкин.

— Менә шул ерткыч пәйда булыр алдыннан Сусылулар тирә-яктагы вак күлләргә, елгаларга күчкән. Ә яр буендагы җен-периләр, диюләр тау-таш арасына качалар яисә җәйләүләргә якын килеп урнашалар, ди. Аларның кешеләргә еш күренә башлаулары да шуннан икән.

Мәргән карашын Атанбайга төбәгән:

— Бәлки, аны... Аждаһа белән сугыштырып булыр?

— Юк, юк, — дип бүлдергән тегесе. — Бу мөмкин түгел — алар икесе дә кара көчләр!

— Мин хәзер үк Төпсезкүлгә китәм.

— Ашыкма, улым, — дигән Атанбай. — Гомерлеккә исеңдә калдыр: бервакытта да төнге учакка туры барма. Башта читләтеп кенә урап чык, күзәт. Хуҗаларның кем икәнен яхшылап төшенмичә, якын барма.

— Аңлашылды.

— Ә хәзер игътибар белән тыңла. Төнге сунарда. Тарканды күлендә булды бу хәл. Таң атып килә иде. Шунда, таш өстендә, уйланып утырган Сусылуны күреп шаккаттым.

— Сусылу? — Мәргән, сөеңеченнән камчы алып, шартлатып җибәргән. — Мин аны һичшиксез эләктерәчәкмен!

Атанбай бераз сүзсез торган. Аның шундый гадәте булган, диләр.

— Борынгы йола буенча, — дигән ул, яшь батырга карап, — Сусылуга кул күтәрү түгел, карарга да ярамый. Югыйсә бәла-каза килерен көт тә тор...

Мәргән башка эндәшмәгән. Йолаларны, гореф-гадәтләрне бозу аучылар арасында хыянәткә тиңләнүен яхшы белгән ул. Тик... яшь йөрәк түзәмени?!

Йокларга яттылар, ди, болар. Берчак, төн урталары җиткәч, коточкыч тавыш яңгыраган. Күк күкри диярсең. Хәтта аяк астында җир селкенгәндәй тоелган. Мәргән озак уйламаган, коралларын алган да, Толпарына атланып, Төпсезкүл ягына



җилдергән. Барып җиткәч, атын акланга җибәргән дә үзе кыя башына менеп утырган.

Тирә-як тып-тын, ди. Тик күл генә сәер күренгән. Күңелгә шом салып, күбекләнеп тора икән. Ә каршы якта бихисап мәһабәт йөзьяшәр наратлар тамырлары белән актарып ташланган булган.

Таң атканчы утырган Мәргән. Акрынлап аның уйлары Еланбалыктан Сусылуга күчкән, ди.

Шул ук көнне, кояш баегач, яшь батыр җәяүләп Тарканды күленә юл алган. Саф, салкын сулы бу күл бик зур да түгел, аңа тирә-яктагы тау чишмәләре кушыла икән. Шул чишмәләрнең иң зурысы янында Мәргән алты төн саклаган, ди, Сусылуны, дөрес булса. Тик юкка гына — күл өстендә кыз түгел, хәтта сикереп уйнаган балык та күренмәгән.

Җиденче төн башланган. Ай да бу төндә яктырак балкыган, йолдызлар да бихисап күбәйгәннәр. Шунсы гаҗәп: күл өсте көзгедәй ялтырый икән...

Төн урталары җиткәч, кинәт күктән йолдыз атылган. Ул шундый зур булган, ди, янып бетәргә өлгермичә, Тарканды күленә барып төшкән. Мәргән чишенеп суга чумган да Йолдызташны эзләгән. Тик күл төбендә вак комнан башка бер нәрсә дә булмаган. Сәер, гаҗәпләндерерлек хәл бит инде бу! Шулчак су өсте дулкынланып киткән һәм

Мәргәннең алдына Сусылу үзе калкып чыккан. Ул шундый сылу икән, яшь батыр, каушавыннан, телсез калган. Озын чәчләреннән мөлдерәп су ага икән теге кызның. Тешләре энҗе кебек ялтырыйлар, ди. Ә күзләренең серлелеген тел белән генә аңлатырлык түгел икән.

Сусылу, батырга кулын сузып, учын ачып җибәргән. Анда йолдызташ ята икән.

— Мә, ал, — дигән ул, соклангыч матур тавыш белән, — муеныңа тагып йөрт — көч-куәт, гайрәт бирер ул сиңа!

— Тагын кайчан очрашабыз, Сусылу?

Кыз егеткә елмаеп караган да:

— Мин Сусылу түгел, ә сихерләнгән җир кызы. Сиңа күренгәнем өчен, кара көчләр мине Аждаһа тавына ябачаклар, шунда килерсең.

— Китмә... — дигән Мәргән һәм сылу кызга якынаерга уйлаган. Ләкин аякларын кузгата алмаган. Кызның сихерләнгән булуының берәр хикмәтедер инде бу.

— Ә хәзер мине игътибар белән тыңла, — дигән Сусылу, егетнең күзләренә карап. — Яңадан ай туып, кабат бүгенге кебек балкыгач, Кушкаен янындагы акланга кил. Анда кәрлә диюләр җыелыр. Азактан Мөгезле дию да очып килер. Син шуны эләктерергә тырыш. Тик мөгезенә тотынма, югыйсә үзең харап булырсың. Кара аны, сак бул. Калганын аннан сорарсың.

— Рәхмәт, чибәр кыз!

— Мин сине җиде төн күзәттем. Син — кыю егет!.. Хуш!

— Китмә, Сусылу!..

Мәргән Сусылуны башка көннәрдә дә, төннәрдә дә көткән, имеш. Йолдызташны да муенына тагып йөрер булган, ди. Атанбай остазы да аңа каршы килмәгән. Яшь егетнең мәхәббәт утында янганын һәм аның, кайчан да булса Аждаһа тавына барып, сөеклесе Сусылуны коткарачагына чын күңеленнән ышанган ул.

Менә шулай көннәр бер-бер артлы үтә торган. Төнге сәер тавыш та һаман кабатлана икән. Күктә ай да тулып бара, ди. Алдагы төндә акланда диюләр җыелырга тиеш бит инде болай булгач. Мәргән дә... Хәер, ансы яшь батырның алдагы маҗарасы бит әле.



БАКЫРҖАН



Сусылу билгеләгән төн җиткән. Мәргән кояш баегач ук Кушкаенның иң юан ботагына менеп яшеренгән.

Төн уртасы җиткән. Күктәге ай, түп-түгәрәк булып, көмештәй ялтырый икән. Кинәт көчле җил чыккан һәм күз ачып йомган арада, чәрелдәшеп-куышып акланга кәрлә диюләр килеп тулган. Алар ямьсез кычкырып, котырып уйный башлаган. Шулчак аклан өстендә көчле давыл купкан. Кәрлә диюләр, карашларын күккә төбәп, шатлана-шатлана бии башлаганнар. Бу гарасаттан Кушкаенның да ботаклары җиргә тигәнче бөгелгән, ди. Бераздан аклан өстендә Мөгезле дию пәйда булган. Канатлары булмаса да оча, гәүдәсе дәү булмаса да, башка сихри затлар аңардан котырынып кача, имеш. Ә маңгаендагы мөгезе ай нурында асыл таштай ялтырый, ди. Шул пәри заты аклан өстендә зырылдап әйләнгән дә Кушкаен янына килеп төшкән. Мәргән озак уйламыйча, корбанына ташланган ерткыч кебек, аның җилкәсенә сикергән. Мөгезле дию Уралны яңгыратып үкереп җибәргән. Аның килбәтсез тавышыннан кәрлә диюләр качып беткән, ди.

Әллә ниләр кыйланып та, батырны егып төшерә алмагач, пәри заты биек кыя янына очып килгән. Аның хикмәтен Мәргән азактан гына аңлаган. Мөгезле дию кыяга якынлашу белән, ни сәбәптәндер, ташлар ачылып киткән һәм алар төпсез караңгылыкка кереп югалганнар. Күп тә үтмәгән, алда гаять зур, күз явын алырдай искиткеч дөнья барлыкка килгән. Монда һуш китмәле пөхтәлек, чисталык, гүзәллек икән. Тоныкь сулы зур күлдә төрле төстәге мәзәк кыяфәтле кошлар йөзә, ди. Ә яшькелт-сары урманда, адәм затларының күзләренә күренмәгән киекләр ял итә икән. Якында гына, тирә-якка нурлар сибеп, бакыр сарай ялтыраган.

Мөгезле дию җиргә төшмәгән, туп-туры күлнең уртасына чумган. Кире су өстенә чыксалар, батыр шаккаткан — кочагында пәри заты түгел, ә үзе кебек гәүдәле егет басып тора, имеш.

— Мин, җир асты тылсымчысы Бакырҗан булам, — дигән ул, ярга йөзеп чыккач. — Ә син кем буласың, адәм баласы?

Мәргән Бакырҗанга баштанаяк карап чыккан да:


— Мин ятим бала — табылдык. Ата-бабамны, әнкәемне белмим. Исемем Мәргән булыр!

— Аңлашылып бетми, — дигән егет, аптырап. — Син Аждаһаның җанын аласы батыр юлыннан барасың. Тик, бу безнең күрәзәчеләр инкарь иткән чынбарлыкка каршы килә.

Мәргән егетнең күзләренә караган.

— Дус итсәң, төрткәләмә, аңлатып сөйлә, — дигән.

— Безнең белүебезчә, — дип сөйләп киткән Бакырҗан, — Аждаһаның җанын аласы батыр Урал тавының гүзәл почмагындагы Тарканды күленнән ерак түгел



урнашкан авылда туган булган. Тик, моны алдан белгән кара көчләр, малайны әнкәсе белән урлап, әле дә булса Аждаһа тавының иң тирән зинданында ябып тоталар.

— Бу вакыйгага минем ни катнашым бар?

— Хикмәтнең асылы шунда! — Бакырҗан сораулы карашын Мәргәнгә төбәгән. — Син өч сынауның икесен каршылыксыз үттең — мөгеземә тотынмадың һәм дә безнең капка аша үтә алдың. Барысы да туры килә, тик... Аждаһаның җанын аласы егетнең күкрәгендә күктәге туганым җибәргән Йолдызташ булырга тиеш иде.

Мәргән күлмәк астыннан Сусылуның бүләген алып Бакырҗанга сузган.

— Шушы түгелме?


Бакырҗан, бүләкне җентекләп караганнан соң, батырны кочаклап алган да:

— Чынлап та, якты дөньяны кара көчләрдән азат итәсе каһарман егет син икәнсең, — дигән.

— Зинһар, озакка сузма. — Мәргән түземсезләнеп кабат кылычын суырып алган. — Илтеп куй мине шул җәһәннәм тавына.

— Кабаланма, батыр! Синең башта Еланбалык белән алышасың, төрле сынаулар, маҗаралар аша үтәсең бар. Ә хәзер син минем кунак! Киттек!

Шул сүзләрдән соң Мәргән, тәмам тынычланып, Бакырҗан артыннан сарайга кереп киткән.



ЕЛАНБАЛЫК



Мәргән бер ай кунак булган. Шул вакыт эчендә батыр ашап-эчеп кенә яткан дип уйлый күрмәгез тагын. Бакырҗан егеткә яңа серләр ачкан, шомлы тау куышларында, кара урманда куркыныч йөзле, әкәмәт күзле, ыржайган тешле җан ияләрен күрсәтеп, аның тәмам котын алып бетергән.

— Ай буена үзеңнең курку хисләреңне җиңәргә өйрәндең, — дигән Бакырҗан, канәгать елмаеп. — Ә бүген төнлә беренче теләгең кабул булыр. — Төпсезкүлдә Еланбалык белән күзгә-күз очрашырсың.

Мәргән шатлыгыннан кычкырып җибәргән, ди, дөрес булса.

— Бернинди корал да кирәкми, — дип, сүзен дәвам иткән Бакырҗан. —

Еланбалык ярга шуышып чыккач, назлап, ләззәтләнеп шул хәшәрәтне мактау җитә.

Мәргәннең йөзендә канәгатьсезлек билгеләре чагылган.

— Шул гынамы? — дигән ул. — Сүз белән тел осталары гына көрәшә.

Бакырҗан сүз көрәштермәгән, сикереп суга чумган да, аннан Мөгезле дию кыяфәтенә кереп, кире чыккан. Күктәге ай, теге төндәге кебек, түп-түгәрәк икән. Мөгезле дию, Төпсезкүл өстендә әйләнеп очкан да кыя итәгенә төшеп кунган.

— Кабат кайчан очрашабыз? — дип сораган батыр, тегенең җилкәсеннән төшкәч.

— Ай тулган саен мин Кушкаенга киләм, — дигән Мөгезле дию, Мәргәнне кочаклап. — Хуш! Уңышлар юлдаш булсын сиңа!

Батыр күзәтергә уңайлы урын тапкан да ни булырын көтә башлаган.

Башта күл өсте тыныч булган. Ләкин бераздан салмак җил чыгып, кинәт көчәеп киткән. Кыялар артыннан чыккан болыт айны каплап алган. Нәкъ шул мизгелдә, ташлар артыннан, чәрелдәп өч кәрлә дию килеп чыккан һәм Мәргәнгә ташланган. Батырның коралы да юк икән. Пәри затлары да бик бирешеп тормаганнар — рәхәтләнеп сугышалар, ди. Мәргән җитез генә тегеләрнең берсен күтәреп упкынга олактырган. Тик, калган ике дию аның үзен ташлар арасына китереп кысканнар. Нәкъ шулчак Йолдызташ балкып киткән. Моны күреп диюләрнең күзе акайган, котлары очып юкка чыкканнар, ди. Бик вакытлы булган бу. Чөнки шулчакта су өстендә



Еланбалыкның килбәтсез башы күренгән. Баканыкын хәтерләткән авызыннан озын теле, ыржайган кәкре тешләре тырпаеп тора, ди. Аякларындагы тырнаклары гына да җиде Кушкаен озынлыгы икән. Аның кыяфәтсез йөзен күрмәс өчен генә дә мең алтын бирерлек, имеш. Шулай да Мәргән курку хисләрен җиңеп алган һәм тирә-якны яңгыратып кычкырып җибәргән:

— Син, Еланбалык, сихри дөньяда иң кодрәтле, зирәк һәм акыллы зат икән. Шул дөресме?

Теге зәхмәт яр буендагы агачларны актарып ташлаган җиреннән туктап калган. Бераздан гөбер-гөбер килеп бака тавышы ишетелгән:

— Хак сүз...— дигән.

— Сине җиңәрдәй батыр әле тумаган, дип сөйлиләр.— Мәргән елмаеп куйган.— Монысына ни әйтерсең?

— Нәкъ шулай...

Мәргәнгә болай тел чарлау бер дә ошамаган. Шулай да Бакырҗанның киңәшләрен исеннән чыгармаган.

— Кодрәтле Еланбалык бик теләсә Урал тауларын да җимерә ала дип сөйлиләр,— дигән ул, хәйлә белән.— Тик моңа ышанып булмый суда килеш, ай-һай, моны эшләп буламы икән?

Соңгы сүзләр Еланбалыкның күңеленә ятып бетмәгән. Ул ачуланып ташларны тырнаган да суга төшеп киткән. Мәргән аптырап калган. Шулчакта күл кайный, кыялар селкенә, аяк астында җир тетри башлаган. Бу вакытта биек кыялар Төпсезкүлгә ишелеп төшкән, бөтен тирә-якны су баскан. Мәргән, эшнең асылын аңлап алгач, борылып Кушкаенга таба чапкан. Шулай исән калган батыр.

Кушкаенга килеп җиткәч, Мәргән артына борылып караган. Андагы үзгәрешләрне күреп, батыр шаккаткан, ди. Биек кыялар кечерәйгән, ә Төпсезкүл киңәеп тирә-якка җәелеп киткән, ди. Теге Еланбалык ташлар астында калып, җан тәслим кылган, имеш. Ә күл, үзенең мәйданын, тирәнлеген үзгәртсә дә, халык аның исемен алыштырмаган — һаман да Төпсезкүл дип йөри икән.



АЛТЫНҖАН



Мөгезле дию кыяфәтендәге Бакырҗан нәкъ төн уртасында килгән. Мәргән аны, гадәттәгечә, Кушкаен ботагында көтеп утырган.

Мөгезле дию үзен бу юлы тыныч тоткан. Җилкәсенә Мәргән менеп утыру белән күккә күтәрелә башлаган. Бераздан биек кыялар, Төпсезкүл уч төбендәге кебек кенә күренгән. Очкан саен йолдызлар да зурая барган. Берзаман тирә-якка яктылык сипкән ай да түбәндә торып калган, ди. Хәтта җир дә ерактан сүлпән генә янган йолдызны хәтерләтә икән.

Алда томанлык күренгән. Аның теге ягында галәмәт гүзәл, күз явын алырдай якты дөнья җәелеп ята, ди. Бакырҗан кызгылт хәтфә үләнле, янар чәчәкләр белән тулган акланга килеп төшкән. Шунда зифа буйлы, көләч йөзле, каһарман гәүдәле егет басып тора икән.

— Мин — күктәге тылсымчы Алтынҗан булам,— дигән ул Мәргәнгә, кулын биреп.— Ә Бакырҗан — минем туганым.

Алар кочаклашып күрешкәннәр. Шуннан соң Мөгезле дию егетләр белән саубуллашкан да юкка чыккан, ди.

Мәргән сокланып тирә-якка күз салган. Монда барысы да ят, үзенчәлекле, төсләр дә җирдәгечә түгел икән. Үсемлек ботакларындагы янар чәчәкләр акрынлап мәрҗән ташларга әверелә,ләр, ди. Мәргән күңелендәге хисләрен тыя алмыйча:

— Асылташлар иледер бу! Байлыктан күзләр камаша! — дип пышылдап куйган.

— Дөрес,— дигән Алтынҗан, аның сүзләрен куәтләп.— Син минем илдә үзеңдә булган комсызлыкны, байлыкка хирыслыгыңны җиңәргә өйрәнерсең. Шул хисләреңне үзеңә буйсындыра алмыйча, Аждаһа мәгарәсенә төшү мөмкин түгел.

Тамак ялгап алгач, Алтынҗан кунакны сарай буйлап алып киткән. Мәргән баштарак үзен төш күргәндәй хис иткән, ди. Чынлап та, адәм баласы ышанырлык хәлмени бу?

Башка көннәрне дә шулай кабатланган. Сарай хуҗасы Мәргәнгә күңеленә ошаган асылташларны кулына алып карарга, кесәсенә салып йөртергә рөхсәт иткән. Бу гади генә күнегү булмаган, әлбәттә. Озакламый моны батыр үзе дә сизгән. Тора-бара аның асылташларга исе китми башлаган.

Көннәрнең берсендә Алтынҗан Мәргәнне биек кыя янына алып килгән.

— Хәзер мәгарә ачылыр,— дигән ул, хәйләкәр елмаеп.— Эчкә кергәч, берничә кагылмыйча, тавышларны ишетмичә, син кире урап чыгарга тиеш буласың.

Соңгы сүзне әйтү белән, мәгарә авызы ачылып киткән. Мәргән, сак кына атлап, эчкә үткән. Мәгарә ябылгач, тирә-якны караңгылык биләп алган. Йолдызташ яктысында, як-якта асылташлар җемелди башлаган. Мәргән, монданиндидер хәйлә



барын аңлап, бик сак кына кыланган. Батыр, мәгарәнең теге башына барып җиткәч, бераз тынычланып кире борылган.

— Мәргән!..

Тавыш, кайтаваз булып кат-кат яңгырап, юкка чыккан. Батыр аптырап туктап калган. Алтынҗанның кисәтүен онытмаса да, ул артка борылмыйча булдыра алмаган — тавыш шундый таныш, якын булган. Ялгышмаган Мәргән — янында гына басып торган Сусылуны күреп, телсез калган. Аның колакларына таккан алкаларыннан зыңгылдап матур тавышлар чыга, муенындагы гәүһәр ташлардан нурлар чәчелә икән. Кинәт Йолдызташ җемелди башлаган. Батыр моңа игътибар итмәгән, сылукайга килеп кагылган һәм таш сынга әверелеп катып калган диләр, дөрес булса.

...Салкынча җил исеп куйган. Мәгарәдә калган Мәргән, ниндидер могҗиза белән киң яланда, чәчәкләр арасында йокысыннан уянып киткән. Янында, көлеп, Алтынҗан басып тора икән.

— Кызганыч, сынауны үти алмадың,— дигән ул, башын селкеп.— Исеңдә калдыр, батыр. Мин җибәргән Йолдызташ сихер белән күзгә-күз очрашканда җемелди яисә төсен үзгәртә.

— Рәхмәт, Алтынҗан,— дигән батыр, авыр көрсенеп.— Башка чакта алырмын.

— Ә хәзер ял ит. Алда сине зур сынаулар көтә.

Алтынҗанның тылсымлы сүзләреннән соң, Мәргән яшь бала кебек рәхәтләнеп йоклап киткән, ди.



ГАЛӘМ КОШЫ



Мәргән йокыдан яхшы кәеф белән уянган. Алтынҗан , елмаеп, кабат аның янында басып тора икән.

— Бүген Галәм кошы оясына кайтачак,— дигән ул. — Соңлап куймыйк.

— Галәм кошы?

— Әйе,— дип, сүзен дәвам иткән Алтынҗан.— Ул тирә-якта балкып торган йолдызларны сүндереп көн күрә, безгә яшәргә комачаулый.

— Сез бит тылсымчылар,— дигән батыр, гаҗәпләнеп.— Шуны җиңә алмыйсызмы?

— Дөрес әйттең — тылсымчылар, ә сугышчылар түгел. Аннан соң, ул яшәгән кара йолдыз, сихри боҗра белән уратып алынган. Анда син һәм бик ерак йолдыздан канатсыз тимер кошка утырган кешеләр генә үтеп керә ала.

— Өлешемә төшкән көмешем,— дигән батыр, канәгать елмаеп.— Минем эш нидән гыйбарәт?

Алтынҗан кесәсеннән савыт чыгарган.

— Мин сине боҗраның бу ягындагы кошка утыртып җибәрәм,— дигән ул.— Кош оясына төшеп йоклап киткәч, аның күз кабагына шушы исле майны сөртерсең.

— Шушы гынамы? — Мәргәннең йөзендә шатлык билгеләре юкка чыккан.

— Әйе,— дип җавап биргән Алтынҗан, хәйләкәр елмаеп.— Шуны эшли алсаң, кош үзенең бердәнбер күзеннән язачак. Бу аның өчен үлем белән бер. Тик кара, батыр, син ничек тә кош белән боҗраның бу ягына кире чыгарга тиешсең. Югыйсә мәңгегә Кара йолдызда торып калачаксың.

Алтынҗан Мәргәнне җилкәсенә утыртып алган да очып киткән. Күп тә үтмәгән, еракта галәмәт зур кош күренгән. Аның бердәнбер күзе генә дә Төпсезкүл зурлыгында булган, имеш. Кошның, канатларын җәеп, тыныч кына очкан чагын көткәннәр.



— Игътибарлы бул,— дип, кабат кисәткән Алтынҗан егетне кошның өстенә төшергәндә.— Мин сине шушында көтәрмен.

Мәргән тирә-якка күз салган. Баксаң, монда үзе бер дөнья икән. Кошның озын каурыйлары Урал тавындагы наратлардан да озынрак, ди. Җитмәсә, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы булган. Тагын Йолдызташ ярдәмгә килгән. Батыр шуның яктылыгында алга атлаган.

Бераздан кош тынып калган. Мәргән, Алтынҗан кушкан эшләрне башкарып бетергән дә кире каурыйлар арасына кереп китәргә ниятләгән. Тик ерак китә алмаган, каршысына ямьсез тешләрен ыржайтып, унике тәпиле җанвар килеп чыккан. Үзе җирдәге үрмәкүчне хәтерләтә икән. Ике ара кыскара барган. Батыр артка чигенергә мәҗбүр булган. Корал белән каршы торуның файдасыз икәнен Мәргән тиз аңлаган. Югалып калмаган егет, кылычын алган да аяк астына китереп кадаган. Шуны сизеп, кош тәпие белән теге җанварны тырнап төшергән дә кабып йоткан. Аның шаукымы Мәргәнгә дә эләккән — батыр, чайкалып китеп, аска тәгәрәгән. Ә кош ачы кычкырып югарыга күтәрелеп юкка чыккан.

Шулай торып калган Мәргән Кара йолдызда. Хәрәкәттә — бәрәкәт дигәндәй, батыр алга атлаган. Тик, бик озын юл үтсә дә, ташлардан башка берни күрмәгән. Арыган, алҗыган батыр, аптырап, таш өстенә менеп утырган. Шулчак батырның күзенә якында гына кәрлә кеше күренеп калган, имеш.



ТАШБАЙ



Мәргән сискәнеп киткән. Чынлап та, янәшәдә генә, таш артына посып, бик бәләкәй буйлы кеше утыра, ди.

— Мин — ташлар иле хуҗасы Ташбай булам,— дигән ул, батыр алдындагы калкулыкка менеп.— Син минем халкымны һәм йолдызыбызны иң явыз дошманыбыздан коткардың. Сора, кыюлыгың, каһарманлыгың өчен ни бирик, батыр егет?

Мәргән башта Ташбайны баштанаяк җентекләп карап чыккан. Азактан, үзе дә бик үк ышанып бетмәсә дә, фикерен ташлар иле хуҗасына әйтеп карарга булган.

— Миңа ничек тә, — дигән ул,— бөҗраның аргы ягына чыгарга кирәк.

Бу сүзләрне ишеткәч, Ташбайның чырае сытылган, ди. Шулай да ул бераз уйланып торган да кул хәрәкәте белән зур ташны читкә күчереп куйган.

— Сине анда чыгарыр өчен,— дигән ул, авыр уфтанып,—илнең иң кадерле байлыгы — гасырлар буе сакланган орлыклар, үсемлек бөртекләре белән хушлашырга туры киләчәк.

— Зинһар, аңлатып сөйләгез,— дигән Мәргән, елмаерга тырышып.— Монда ил байлыгының ни катнашы бар?

— Бердәнбер өмет Шок кошына,— дип аңлаткан Ташбай Мәргәнгә.— Тик аны монда төшерер өчен бик күп орлыклар, бөртекләр кирәк.

— Димәк, очкан кошны монда төшерү кирәк?


— Дөрес, батыр егет.— Ташбай канәгать елмаеп куйган.— Ул ашаган арада сиңа аның аягына ябышырга кирәк. Бәлки, Шок тимер кешеләр ягына очадыр?!

— Тимер кешеләр? — Мәргән бераз уйланып торган. Аның йөзе җитдиләнгән, ди. — Юк, сезнең тарафтан бу бик зур корбан була.

— Башка чара юк,— дигән өзеп кенә Ташбай. Аннан күчкән таш ягына карап кычкырган: — Ил байлыгын монда чыгарыгыз!

Шулчак, җилкәләренә савытлар күтәреп, тау тишегеннән ташкын кебек кәрләләр чыга башлаган. Алар, күз ачып йомган арада, хуҗаларының боерыгын җиренә җиткереп үтәп тә куйганнар.

Ташбай моны ихлас күңеленнән эшләсә дә, Мәргән бу хәлгә һич кенә дә риза



булмаган. Шуңа күрә ил байлыгын саклап калыр өчен, батыр төрле хәйләләр кора башлаган.

Әмма кош та үзен озак көттермәгән. Аны күрүгә, кәрләләр батыр белән саубуллашканнар да тау тишегенә кереп качканнар.

— Рәхмәт, батыр! — Ташбай Мәргәнгә карап баш игән.— Күп тә үтмәс, безнең йолдыз яңадан балкып янар, ышан безгә.

Кош ояга төшү белән, Мәргән аның аягына ябышкан һәм, берничә укны төзәп, тегенең томшыгыннан асылынып торган теленә атып җибәргән. Шок, авыртуга чыдый алмыйча, пырхылдап күтәрелеп киткән, имеш.

Менә шулай сакланып калган ташлар иленең казнасы. Мәргән дә, исән-сау килеш, каядыр очып киткән. Ниһаять, алда җемелдәп утлар күренгән. Батырның күңелендә кабат котылу өмете туган, ди.



ФОАБИС




Бу тиклем төрле төстәге утларны Мәргәннең беркайчан да күргәне булмаган. Шулай сокланып карап барганда, астан кошка тиклем ут җебе сузылган һәм Шок, башын, канатларын салындырып, түбән тәгәрәгән. Мәргән дә, кулларын ычкындырып, әйләнеп-әйләнеп өемгә килеп төшкән. «Кара йолдыз таштан гына тормый икән,— дип уйлаган ул, яткан урынын капшап.— Әллә туфрак инде?..»

Батыр куанычыннан сикереп торган. Учындагы туфракны исни-исни утлар ягына юл алган. Барса, үз күзләренә ышанмый тора икән: көчле ут яктысында, шакмак башлы, өч аяклы, сәер гәүдәле җан ияләре йөри, ди. Яннарында төрле зурлыктагы шарлар оча икән. Алар барысы да, мәйдан уртасында торган Аждаһа тавыдай, дәү канатсыз кошка кара туфрак — тере җир тутыралар, ди.

Мәргән хәтсез генә тегеләрне күзәтеп торган. Мәйдан уртасында биек багана тора икән. Ә аның очында күз явын алырдай ут балкып торган.

Шулчак тирә-якка ут җепләре сузыла башлаган. Киткән кычкырыш, ызгыш. Тиз арада мәйдан төрле җан ияләре белән тулган. Озын кешеләр уртадагы баганага якынаерга тырыша, ә тимердән эшләнгәннәре аларның юлларын каплыйлар, ди. Батыр шул чакта өстә янган утның ниндидер хикмәткә ия булуын төшенеп алган. Шик



юк, Мәргән күңеле белән башта ук озын кешеләр ягында булган. Шуңамы, алышның иң кызган мәлендә, яшеренеп кенә багана башына менгән дә кылычы белән теге утка китереп тондырган. Зыңгылдап пыяла коелган һәм тирә-якны шомлы караңгылык биләп алган. Мәргәннең күкрәгендәге Йолдызташ кына нурлар чәчеп балкып тора, ди.

Шулчак баскычтан кара бөдрә чәчле, киң күкрәкле мөлаем кеше йөгереп менгән.

— Мин Фоабис атлы булам,— дигән ул, кулын сузып.— Ә син тышкы кыяфәтең белән Җир кешесенә охшагансың. Рәхмәт, безне әсирлектән коткардың.

Мәргән кулын биреп исемен әйткән. Әле һаман да, мондагы хәлләрнең асылын аңламаганга күрә, сораулы карашын Фоабиска төбәгән.

— Тимер кешеләр — роботлар, явыз планета вәкилләре,— дип сөйләп киткән тегесе тыныч кына.— Алар мондагы кара туфракны урлап ташыйлар. Ә безне, Зәңгәр йолдыз кешеләрен, сугышып, әсирлеккә алдылар да монда кара эшләрен эшләттеләр.

— Аңлашылды,— Мәргән карашын Фоабисның кулындагы ике катлы көпшәгә күчергән. — Монысы нинди корал?

— Бу — лазер автоматы.— Фоабис аста көтеп торган халыкка карап кул болгаган. Тегеләр тезелешеп тимер кошка төялә башлаган. — Без электән дә баш күтәреп карадык.— Тик аларның барысы да уңышсыз тәмамланды. Багана башындагы энергия чыганагыннан роботлар үзләренә көч алалар иде, нык сакладылар. Ә син аны челпәрәмә китердең. Туган ягыбызга киткәнче синең алда бурычыбызны үтисебез бар. Әйт теләгеңне, батыр!

— Бердәнбер теләгем,— дигән Мәргән, моңсуланып,— туган төбәгемә — Уралыма кайту.

— Килештек.— Фоабис Мәргәннең кулын кыскан.— Безнең юллар бер якка. Киттек, батыр!

Тимер кош янына төшкәннәр болар.

— Космик корабльгә рәхим ит, Мәргән,— дигән Фоабис, аны алдан үткәреп.

Эчкә үткәннәр. Як-якта утлар җемелди, сәер тавышлар чыга икән. Зур салонга кереп, креслоларга утырганнар.

— Монысы идарә үзәге, — дип аңлаткан Фоабис, алдындагы кнопкаларга басып.— Хәзер корабль белән компьютер җитәкчелек итә.

Стеналардагы пыялаларда җанлы сурәтләр, саннар, сызыклар барлыкка килгән. Фоабис җиңел сулап куйган.

— Без — азат! — дигән ул, Мәргәнне кочаклап.— Без галәмгә чыктык. Юнәлеш — Җир!

Күп тә үтмәгән, Фоабис урыныннан торган.

— Безгә саубуллашырга вакыт җитте, батыр,— дигән ул, Мәргәнне салон читендә торган шар янына алып килеп.— Шушы иярченебез сине туган төбәгеңә илтеп куяр.


Шар уртасында ишек ачылган. Мәргән барысы белән дә саубуллашкан да эчкә кереп утырган. Ниндидер утлар сүнеп янгач, ишек кире ачылган.

— Сау бул, батыр,— дигән тавыш ишетелгән кайдандыр.— Ачуланып калма, юлыбыз ерак, без китәбез.

Ут шары күздән югалгач, Мәргән як-якка күз салган. Баш өстендә җемелдәшеп йолдызлар яна, ай да, көмеч кебек, түп-түгәрәк, ди. Каршыда Төпсезкүл җәелеп ята икән. Батырны ниндидер көч Кушкаен янына тарткан. Барса, үз күзләренә ышанмый тора икән — агач төбендә карашын айга төбәп, Бакырҗан утыра, имеш. Кочаклашып күрешкәннәр, ди, дуслар.

— Нәкъ вакытында кайттың,— дигән Бакырҗан шатлыклы тавыш белән.— Югыйсә Аждаһа тавының мәгарә капкасы ябылыр иде.

Мәргән башыннан кичкәннәрне төкми-чәчми дустына сөйләп биргән. Шуннан соң Бакырҗан Мәргән батырны Аждаһа тавына алып киткән.



АЖДАҺА




Тау итәгенә җиткәч, Бакырҗан Мәргәннең алдына чыгып баскан.

— Игътибар белән тыңла,— дигән ул.— Мәгарә бик тирән урнашкан — озак барырга туры килер. Дөрес аңла, анда бернинди дә Аждаһа юк — ә кара, сихри көчләрне берләштергән йөрәк бар — шуны юкка чыгарырга кирәк! Сак бул, дустым! Йолдызташ — маяк, сүзләрем васыять булсын! Хуш!

Бакырҗан торган җиреннән мәңгелеккә юкка чыккан. Мәргән, авыр уфтанып, Аждаһа тавына күз салган. Ямансулаган егет. Ни эшлисең бит, якын дустың белән аерылышу җиңел түгел шул! Җитмәсә, нинди фикердәш, юлдаш бит — сокландыргыч саф күңелле, ихлас, тәвәккәл акыллы җан иясе!

Мәргән Аждаһа тавына күз салган. Ничә гасырлар адәм баласының күңеленә шом салган, бихисап батырларның гомерен өзгән кара көчнең асылы менә нидә икән?!

Мәргән, кылычын алган да, караңгы тишеккә кереп киткән. Гасырлар буе кояш күрмәгән, мүкләнгән ташлардан салкын бөркелеп тора икән. Аларның очлы, үткер сыртларына бәрелеп, батырның куллары, аяклары җәрәхәтләнгән. Йолдызташ та эчкә үткән саен яктырак яна, ди. Бераздан тишек зурая башлаган. Алда нидер ялтырап киткән. Бу зур буар еланның күзләре булган. Аралар якынайган саен, Йолдызташ та ныграк балкый икән. Елан да зәһәр, ди — үткен тырнаклы сигез аягы бар, имеш. Атанбай остазы сөйләвенә караганда, бу сихри зат та күпләрнең гомерен өзгән. Дөрес булса, ул элек-электән Төпсезкүл янында еш күренә торган булган.



Мәргән һөҗүм итәргә уңайлы мизгел көткән. Елан да куркак заттан түгел бит инде. Әмма ул, ысылдап, өзлексез артка чигенгән. Батыр еланның Йолдызташтан шүрләвен башта ук аңлап алган. Сусылуның бүләген ташка элеп куйган да үзе читләтеп кенә теге сихри затка якынлашкан. Шулчак кылыч ялтыраган һәм еланның башы кыелып төшкән. Шулай җиңгән батыр тегене. Азактан, Йолдызташын алган да, корбанның җансыз гәүдәсе аша атлап, алга киткән. Ниһаять, каршыда бәләкәй күл күренгән. Мәргән юынып алырга уйлаган. Тик, Йолдызташ җемелди башлагач, ары атлаган.

— Мәргән!

Батыр артка борылып караган һәм шаккаткан — күл читендәге ташта, Алтынҗан мәгарәсендәге кебек, кабат Сусылу утыра икән.

— Килдеңме, җаным? — дигән ул Мәргәнгә.— Алып кит мине бу җәһәннәмнән.

Алтынҗан юкка сынау үткәрмәгән шул. Югыйсә мондый сихергә каршы торып булыр идемени?

— Күкрәгеңдә нинди асылташ ул? — дип сораган кыз. — Капла, күзне чагылдыра.

Мәргән дертләп куйган. «Әгәр чынлап та Сусылу булса,— дип уйлаган ул,— Йолдызташны танымас идемени?»


Шулчак ысылдаган тавыш ишетелгән. Батыр борылып караса, әле генә Сусылу утырган таш өстендә бөгәрләнеп кара елан ята, имеш. Батыр кылычы белән сихри затны тураклаган да алга киткән.

Акрынлап тирә-якта асылташлар елкылдап җемелди башлаган. Алар ниндидер тылсымлы көч белән егетне үзләренә тарталар икән.


Мәргән адымын кызулаткан. Йолдызташ та, кызып, батырның күкрәген өтеп-өтеп ала икән. Димәк, Аждаһага ерак калмаган. Чынлап та, алтыннар белән түшәлгән залда асылташлардан төзелгән Аждаһа сыны ята икән. Мәргән бер мизгелгә туктап калган. Моңа тиклем күрелмәгән гүзәллеккә карап хәйран калган батыр. Кинәт Йолдызташ аның күкрәген яндырып алган. Мәргән, авыртуга чыдый алмыйча, кылычы белән Аждаһаның кара йөрәгенә китереп тондырган. Тирә-якка асылташлар сибелгән, мәгарә гүелди башлаган. Җан сыкраткыч ысылдаулар, сәер сызгырулар яңгыраган, диюләрнең ыңгырашканы, албастыларның үкереп елаганы колакны ярган.

Бераздан тирә-якта тынлык урнашкан. Йолдызташ та сүрелгән. Арыган, йончыган батыр таш өстенә утырып, кылычына таянган да йоклап киткән.

Сәер төш күргән Мәргән. Әйтерсең ул — күкрәк баласы, ә ниндидер гүзәл хатын, аны имезеп, бишек җыры җырлый, имеш. Ә малай, аның ягымлы тавышыннан уянмыйча, йоклый да йоклый, ди.



ЯШӘГӘН, ДИ, БЕР БАТЫР



Озак йоклаган Мәргән. Уянып күзләрен ачса, аптырап киткән — төшендәге бишек җыры һаман да яңгырый икән. Батыр шул тавышны эзләп киткән. Алда, караңгы почмакта зур таш ишекләр тезелеп киткән, ди. Мәргән шуларның беренчесен каерып ачып җибәргән. Моң шунда өзелгән. Дөньяның ачысын да, төчесен дә татыган батыр югалып калган — каршысында үзенә су тамчысы кебек охшаган егет басып тора икән. Шулчак почмактан чал чәчле хатын чыккан.

— Килдеңме, улым,— дигән ул, Мәргәнне кочаклап.— Унсигез ел буе көттем мин сине.

Хатын Мәргәннең аркасыннан сөйгән, чәчләреннән сыйпаган.

— Сез, рамазан аеның җиденче көнендә, игезәкләр булып, якты дөньяга тудыгыз. Кояш баер алдыннан безнең янга ап-ак чәчле әби килеп керде. «Бүген дөньяга, гасырлар буе адәм балаларының котын алган Аждаһаның җанын аласы гайрәтле батырны тудырдың. Тик бу хакта кара көчләр дә белә. Алар төнлә синең арттан киләчәкләр. Сихри затлардан качу мөмкин түгел. Әмма алар синең игезәк улларың туганын белмиләр»,—диде әби. Шуннан соң уң ягымда ятканыгызны алды да аучы Атанбайга тапшырам дип вәгъдә бирде. Атагыз да Аждаһа тавына китеп югалгач, мин риза булдым...

Күзләре яшьләнгән Мәргән башта анасын, азактан туганын кысып кочаклаган. Шул чакта гына батыр Бакырҗанның башта аптыраган йөзен, сораулы карашын, Йолдызташның ничек үзенә эләгүен, кыскасы, барлык маҗараларның һәм могҗизаларның асылын аңлаган. Сихри затларны җиңәсе батыр юлыннан бармаган, ә үзенең тәкъдиренә язылган, алдан сайланган эзеннән барган бит!

Мәргән һәм туганы зиндан ишекләрен ачып, бихисап батырларны азат иткәннәр. Әкиятнең азагы бәхетле, шатлыклы бетә дигәндәй, Мәргәннең әнисе шунда үзенең ирен танып алган, диләр, дөрес булса. Шулай итеп, батыр егет әти-әнисен, туганын табып, зур куаныч кичергән.

Соңгы ишекне ачканнар болар. Мәргәннең шат йөзен борчылу билгеләре басып алган — Сусылу беркайда да юк икән. Аптыраган батыр. Шулчак нишләптер Йолдызташ алга тартылып куйган. Мәргән шул якка атлаган. Читтәрәк, караңгы почмакта бәләкәй генә күл бар икән. Йолдызташ егетне шунда алып килгән.

Шулчак күл өсте чайкалып киткән һәм су өстендә исең-акылың китмәле гүзәл кыз пәйда булган. Мәргән аны шунда ук танып алган.

— Саумы, минем коткаручым,— дигән кыз батырга, кулын сузып.— Тарканды күлендә Йолдызташны бүләк иткәннән бирле көттем сине.

— Мин дә сине бик озак эзләдем.

— Беләм,— дигән кыз, шатланып.

Мәргән, әти-әнисен, туганын элекке Сусылу, хәзерге гүзәлкәй белән таныштыргач, барысын да ияртеп, кайтырга чыккан.

Таң атып килә икән. Урал кыялары артыннан күтәрелеп килгән Кояш, үзенең бетмәс-төкәнмәс нурлары белән, мәгарәдән чыккан адәм балаларын җылытырга



керешкән. Ә таң җиле аларны иркәләп, салмак кына битләреннән, чәчләреннән сыйпап үткән. Таң кошлары, бер-берсен уздырып, сайраргa тотынганнар, ди.

Мәргән тегеләрнең барысын да Атанбай остазы янына алып кайткан, имеш. Шушы шатлыклы вакыйгадан соң, Мәргән сылукайга өйләнгән. Игезәк туганы да, ияреп кайткан батырлар да матур-чибәр кызлар ярәшеп, йортлар салып, күркәм гаиләләр корып җибәргәннәр. Еллар үткәч, шушы урында шаулап торган авыл барлыкка килгән.

Данлы Уралның биек сыртына урнашкан Аждаһа тавы әле дә, башын күтәргән еланны хәтерләтеп, ерак-еракларга күренеп тора. Күп еллар үтсә дә, халык аны элекке исеме белән атый. Авыл балалары шунда барып, җиләк-җимеш, дару үләннәре җыялар, Төпсезкүлгә барып, су керәләр, балык тоталар. Ә өлкәннәр, тау-таш актарып, кайчандыр яшәгән Мәргән батыр күргән асылташларны эзлиләр. Шушы төбәктә яшәгән бабайлар аучы егетнең маҗараларын һаман да онытмыйлар, әле булса балаларга, яшьләргә яратып, горурланып сөйлиләр.



ББК 83.8-Тат 7—4
М 71

Издание для детей и юношества

Мусифуллин Мударрис Гайнельисламович

ПРИКЛЮЧЕНИЯ ОХОТНИКА МЭРГЭНА

Сказка-легенда

(на татарском языке)

Редакторы *Р. Зәһидуллина*. Бизәлеш редакторы *Р. Шәмсетдинов*. Техник редакторы *Н. Мусина*. Корректоры *Г. Зиннәтуллина*. Нәшриятка 0201 нче номерлы лицензия 1997 елның 22 августында бирелгән. Җыярга тапшырылды 28.06.99. Басарга кул куелды 27.09.99. Форматы 60 х 90¹/₈. Офсет кәгазе № 1. «Академия» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,0. Шартлы буяу-оттиск 6,0. Нәшер-хисап табагы 2,89. Тиражы 5000 экз. Заказ 3-321. Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN 5—298—00931—X

© Татарстан китап нәшрияты, 1999



